| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20. 12. 2024 Олы Кайбыч ав. № 476

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 04 июлендәге 309 номерлы карары белән расланган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәт исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы һәм Кайбыч районы прокуратурасының 2024 елның 21 августындагы 02-08-03-2024 номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 04 июлендәге 309 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан ирекле булган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт исемлегенә (алга таба - исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль милек исеменнән төшереп калдырырга:

| т/б | Милек исеме | Бинаның гомуми мәйданы | Урнашкан урыны (адрес) |
|---|---|---|---|
| 4 | 16:21:120401:105 кадастр номерлы 1962 елгы бина (торак булмаган бина) | 53,5 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Яңа Буа ав., Үзәк ур., 49 |
| 5 | 16:21:000000:511 кадастр номерлы клуб бинасы (гамәлдә булмаган) | 143,4 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Подберезье авыл җирлеге, Плетени ав.,Урман ур.,57 |
| 7 | 16:21:140301:286 кадастр номерлы бина (торак булмаган бина, Турминский башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы) | 253,8 | Татарстан Республикасы, Кайбыч районы,Хуҗа Хәсән авыл җирлеге, Турминский ав., Үзәк ур, 47 |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе О.Д. Макаровага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенең беренче урынбасары — Э.Х.Заһидуллина